КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 июнь г.Казань № 398

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын оештыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын оештыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 май, 296 нчы, 2016 ел, 24 май, 341 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турында нигезләмәдә:

10 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгы тәэмин итү комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервы номенклатурасын һәм күләмен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\398.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2008 ел, 11 июль, 488 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 20 июнь, 398 нче
карары редакциясендә)

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘРНЕ БЕТЕРҮ ӨЧЕН МАТДИ РЕСУРСЛАР РЕЗЕРВЫ НОМЕНКЛАТУРАСЫ ҺӘМ КҮЛӘМЕ

| Т/с | Матди ресурслар исеме | Үлчәү берәмлеге | Саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Гадәттән тыш хәлдә зыян күргән халыкның тереклеген тәэмин итүне оештыру | | | |
| 1. | Пневматик каркаслы модуль | комплект | 6 |
| 2. | Палатка | комплект | 105 |
| 3. | Бензинлы һәм дизельле генератор 5 кВт | данә | 3 |
| 4. | Һәлакәттә яктырту җайланмасы (утлы манара) | комплект | 8 |
| 5. | КП-125 тагылма кухнясы | данә | 1 |
| 6. | Чуен мич | комплект | 22 |
| 7. | Җәелмәле караватданә | данә | 500 |
| 8. | Җиңел җыела торган душ бүлмәсе | комплект | 4 |
| 9. | Җыеп куела торган юынгыч (6 кешегә) | комплект | 4 |
| 10. | Җыеп куела торган өстәл | данә | 25 |
| 11. | Җыеп куела торган урындык | данә | 100 |
| 12. | Өс киемнәре, шул исәптән: | данә | 500 |
| | камуфляжлы җылытылган костюм | данә | 200 |
| | мамык куртка | данә | 200 |
| | хатын-кызлар халаты | данә | 100 |
| 13. | Юрган, шул исәптән: | данә | 500 |
| | жаккард | данә | 272 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | йон | данә | 228 |
| 14. | Мамык матрац | данә | 500 |
| 15. | Мендәр | данә | 500 |
| 16. | Урын-җир әйберләре | комплект | 500 |
| 17. | Сырлы сөлге | данә | 500 |
| 18. | Шәхси гигиена әйберләре (теш порошогы, теш щеткасы, сабын, бәдрәф кәгазе) | комплект | 500 |
| 19. | Карабодай ярмасы | килограмм | 150 |
| 20. | Дөге ярмасы | килограмм | 150 |
| 21. | Макарон эшләнмәләре | килограмм | 150 |
| 22. | Томалап пешерелгән консервланган ит | килограмм | 300 |
| 23. | Чәй | килограмм | 3 |
| 24. | Шикәр | килограмм | 30 |
| 25. | Бер тапкыр файдаланыла торган савыт-саба комплектлары (стакан, тәлинкә, кашык) | комплект | 2 000 |
| 26. | Салфеткалар | кап | 20 |
| 27. | Чүп өчен бер тапкыр файдаланыла торган 60 литрлы капчыклар | төргәк | 10 |
| | Гадәттән тыш хәл зонасында коткаручылар төркемчәсен җиһазландыру | | |
| 28. | «Коры» паек | комплект | 200 |
| 29. | Мотопомпа | данә | 70 |
| 30. | Янгын сүндергеч җиңсә (51 мм) | метр | 2 300 |
| 31. | Бензин белән эшли торган пычкы | данә | 6 |
| 32. | Штыклы көрәк | данә | 100 |
| 33. | Соскыч көрәк | данә | 100 |
| 34. | «Казанка-6М» мотокөймәсе | данә | 6 |
| 35. | Егәрлеге 12 а/к кадәр булган элмә көймә моторы | данә | 4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 36. | ДПГ-3 өстәмә патроны | данә | 18 |
| 37. | «Лепесток» респираторы | данә | 100 |
| 38. | Костюм КИХ-4М | данә | 500 |
| 39. | Полипропилен капчык | данә | 8 |
| 40. | Бон киртә | данә | 34 000 |
| 41. | Йөзмә дамба | метр озынлыгы | 500 |
| 42. | Сигнал лентасы | метр | 2 500 |
| 43. | Перчаткалар | данә | 500 |
| 44. | Бер тапкыр кия торган плащ | данә | 500 |
| 45. | Мәетләрне транспортировкалау өчен капчык | данә | 200 |
| Медикаментлар һәм җиһазлар | | | |
| 46. | Махсус медицина җиһазлары һәм дару препаратлары | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә | |
| Төзелеш материаллары | | | |
| 47. | Торак-коммуналь хуҗалык объектларында гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен һәлакәт-техника запасы һәм төзелеш материаллары | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнә | |